Урнашылган гадәт буенча, һәр ел Халыкара олимпиада комитеты әгъзасы, Россия теннисы Федерациясе президенты булган атаклы якташыбыз Шамиль Анвәр улы Тарпищев житәкчелегендә, Саранскта теннис буенча ярышлар vтә.
Быел да март башында Россиянен 47 шәһәреннән 13-17 яшькә кадәр спортсменнар турнирда катнашты. Шул исәптән, Мордовия теннисистлары да.   Ә тагы Халыкара яшvсмерләр турниры да vтте. 13 регионыбызга 12 яшькә кадәр 60 спортсмен турнирга килде.
Ә 14 марта СК «Саранск-Арена»нын тренировка залында Шамиль Анвәр улы Тарпищев булды. Ул яна спорт корылмасында экскурсия кылды, шулай ук Республикабыз Мордовиянен спорт буенча жыелма (сборная) команда вәкилләре шогыльләнгән гимнастика белән хореография залларын да кvреп кайтты.
Саранскида интеллектуаль тайпылышлары булган затлар арасында остәл теннисы буенча Россия чемпионаты һәм беренчелеге старт алды. «Мордовия» спорт комплексы мәйданчыгында чираттагы тапкыр Россиянен 20 тобәгеннән дистәләгән ин кочле спортчы очрашты. Ярышлар 2022 елнын 15-17 мартында узды.